**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат - Асты авылы торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**2025 ел, 19 ноябрь** **№ 2**

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат - Асты авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Нарат - Асты авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 2300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) электр челтәрләренең тышкы яктыртуын ремонтлау, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм аларга якын урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм торак пунктларга электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
2 ) торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нарат- Асты торак пунктында территорияне кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)
3) Нарат- Асты торак пункты территориясен төзекләндерү (триммер, триммер өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу).
4) ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Нарат Асты зираты өчен профиль һәм калай сатып алу)

3.Җыен нәтиҗәләрен Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтынд(https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: И.Н.Хадиуллин